Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге Советы

# КАРАР

№11 22 сентябрь 2017 ел

Ютазы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 22, 56 маддәләренә, 2002 елның 12 июнендәге «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 67-ФЗ санлы Федераль законның 15 маддәсенә, 2004 елның 25 мартындагы «Җирле референдум турында»гы 23- ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсенә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ютазы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе нигезендә, җирлек Советы һәм җирлек башлыгы тарафыннан бергәләп тәкъдим ителгән гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын хуплап, Ютазы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2017 елның 19 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2018 елда Ютазы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган гражданга 150 (йөз илле) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы,Бөек Ватан сугышында катнашучыларны һәм аларга тиңләштерелгән затларны, 1,2 төркем инвалидларны, балачак инвалидларын түләүдән азат итеп, алынган акчаларны карарга җибәрергә ризамы түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләр:

1.Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Ютаза авылы урамнарында торак пункт юлларын (ташу,салу) вак таш белән каплау җайланмасы;

- Ютазы авылы, Ютазы кымыз белән дәвалау шифаханәсе, Ык, Керкале авыллары урамнарын кардан чистарту

2. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Ютаза авылында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (бетондаштыру, койма урнаштыру).

«ӘЙЕ ЮК».

3. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Ютазы авыл җирлеге бюджеты акчалары хисабына тормышка ашырырга.

4. Әлеге карарны «Ютазы таңы» («Ютазинская новь») газетасында бастырып чыгарырга, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә һәм авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Ютазы авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфиуллина